**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2393**
**12.05.2022**

Башкарма комитетның «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасы системасын, халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итүне камилләштерү» муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 28 октябрендәге 7114 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасы системасын, халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итүне камилләштерү» муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 28 октябрендәге 7114 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләр» 01.13, «Халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгы» 03.10, «Су хуҗалыгы» 04.06 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 2022 елда – 2249,90 мең сум, 2023 елда –1949,9 мең сум, 2024 елда –1949,9 мең сум күләмендә тәэмин итәргә»;

2) «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасы системасын, халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итүне камилләштерү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2022 | 2023 | 2024 | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 2249,9 | 1949,9 | 1949,9 | 6149,7 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 2249,9 | 1949,9 | 1949,9 | 6149,7 |

- 3 бүлектә «Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау» таблицасында:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Гидротехник корылмаларның эксплуатация ышанычлылыгын күтәрү буенча чаралар | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | ел дәвамында | Гидротехник корылмаларны авариясез эксплуатацияләү дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 538,8 | 238,8 | 238.8 |

«Барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | | | | | | | 2249,9 | 1949,9 | 1949,9 |

- 6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаның ресурс белән тәэмин ителешен 6149,7 мең сум күләмендә шәһәр бюджеты акчалары тәшкил итә, шул исәптән:

2022 ел – 2249,9 мең сум;

2023 ел –1949,9 мең сум;

2024 ел –1949,9 мең сум.

Программаны тормышка ашыруга ассигнованиеләр кыскарганда яки артканда, программаны башкаручы чаралар исемлегенә төзәтмәләр кертү буенча тәкъдимнәр кертә.

Программаны финанслау күләмнәре прогноз характерына ия һәм билгеләнгән тәртиптә аңа төгәллекләр кертелергә тиеш.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы Р.М. Мингалиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов